Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Иске Шөгер авыл җирлегенең
Иске Шөгер торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 18 ноябре № 1

## Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер җирлеге Иске Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар; сугыш хәрәкәтләре ветераннары; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны кардан чистарту, юлларны грейдерлау, юл кырыенда чүп үләнен чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә итеп оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:
- урам утларын сатып алу һәм алыштыру;
койманы буяу, чәчәкләр һәм куаклар утырту, С. Садри урамындагы һәйкәл янында үлән чабу;
3) халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү:
Яшьләр урамындагы "Яшьлек" паркында үлән чабу, чәчәкләр һәм куаклар утырту;
4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту:
коры һәм чүп үләнен чабу, зират территориясендә иске авария хәлендәге агачларны һәм куакларны кисү (килешү буенча түләү).
ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:
корыган һәм чүп үләнен чабу, иске авария хәлендәге агачларны һәм куакларны кисү (килешү буенча түләү).

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 633 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 320.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 320 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге составына керүче Иске Шөгер торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер җирлеге Иске Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар; сугыш хәрәкәтләре ветераннары; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юлларны кардан чистарту, юлларны грейдерлау, юл кырыенда чүп үләнен чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә итеп оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:

- урам утларын сатып алу һәм алыштыру;

койманы буяу, чәчәкләр һәм куаклар утырту, С. Садри урамындагы һәйкәл янында үлән чабу;

3) халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү:

Яшьләр урамындагы "Яшьлек" паркында үлән чабу, чәчәкләр һәм куаклар утырту;

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту:

коры һәм чүп үләнен чабу, зират территориясендә иске авария хәлендәге агачларны һәм куакларны кисү (килешү буенча түләү).

ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

корыган һәм чүп үләнен чабу, иске авария хәлендәге агачларны һәм куакларны кисү (килешү буенча түләү) соравы буенча карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 нче йорт (җирле үзидарә бинасы), Совет урамы, 3 нче йорт буенча (балалар бакчасы бинасы), М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, Иске Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
“Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова